# КАРАР

**2021 елнын 30 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл жирлегенең Татар Толлысы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар жыены нәтижәсе турында**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 27 ноябрендә 10.00 сәгатьтә һәм 2021 елның 27 ноябрендә 13.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар жыеннары нәтижәләре буенча гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 5 һәм аннан да күбрәк 18 яшькә кадәрге балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл жирлегенең Татар Толлысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Татар Толлысы авылының Үзәк урамында су үткәрү торбалары урнаштыру (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылының Яшьләр урамында юл буенда су агу канавы ясау (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сабантуй уздыру урынын тозеклэндеру (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу;
- Татар Толлысы авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар жыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә 303 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар жыенында катнашучылар саны 160.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен жыенда катнашкан 156 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен жыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар жыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл жирлеге Татар Толлысы авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 5 һәм аннан да күбрәк 18 яшькә кадәрге балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Татар Толлысы авылының Үзәк урамында су үткәрү торбалары урнаштыру (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылының Яшьләр урамында юл буенда су агу канавы ясау (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сабантуй уздыру урынын тозеклэндеру (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу;
- Татар Толлысы авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Чарлы авыл җирлеге башлыгы Э.Н. Козлов

СОВЕТ ЧАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021607752792
ИНН 1623001646